# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 27 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында” 2005 елның 30 декабрендәге 138-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 1, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш), Ватаным Татарстан, 2013, 20 апрель) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2. Субсидия исәпләп чыгару өчен кулланыла торган торак урыны норматив мәйданының төбәк стандарты түбәндәгеләргә карата билгеләнә:
ялгыз яшәүче гражданга;
ике кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына;
өч кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына;
дүрт кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына;
биш һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына.”;

2) 3 статьяның 2 өлешендә:
а) өченче абзацта “җылылык белән тәэмин итү” сүзләрен “җылыту” сүзенә алмаштырырга;
б) дүртенче абзацта “җылылык белән тәэмин итү” сүзләрен “җылыту” сүзенә алмаштырырга;
в) бишенче абзацта “җылылык белән тәэмин итү” сүзләрен “җылыту” сүзенә алмаштырырга;

3) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

“3. Торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр хакының төбәк стандартлары җылыту һәм җылыту арасындагы чорларга, шулай ук законнарда каралган бүтән очракларда дифференциацияле билгеләнә, коммуналь ресурсларга тарифлар календарь буенча бүленгән очракта, шул исәптән мондый бүленеш буенча да билгеләнергә мөмкин.”;

4) 1 нче кушымтаның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр хакының төбәк стандартлары күләмнәре түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$C_{ij} = \mathrm{SUM}_{c=1}^{n} (T_c \times (N_{cj\,тор} + (N_{cj\,бер} \times S_{i\,бер}) \times K_{cj}) + \mathrm{SUM}_{L=1}^{m} (T_L \times K_{Lj} \times S_i),$$

монда:

$C_{ij}$ – хезмәт күрсәтүләрнең j-исемлеге буенча торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр хакының i кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына төбәк стандарты күләме;

$T_{c(L)}$ – коммуналь хезмәт (торак хезмәте) күрсәтүгә тариф (бәя);

$N_{cj\,тор}$ – торак урыннарында j-исемлек буенча коммуналь хезмәт күрсәтүне күпфатирлы йортлар һәм торак йортлар өчен куллану нормативы;

$N_{cj\,бер}$ – j-исемлек буенча коммуналь хезмәт күрсәтүне гомумйорт ихтыяҗлары өчен куллану нормативы;

$S_{i\,бер}$ - күпфатирлы йортларда уртак мөлкәт составына керә торган урыннарның i кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына туры килә торган мәйданы;

$K_{c(L)j}$ – муниципаль берәмлек торак фондының хезмәт күрсәтүләрнең j-исемлеге буенча коммуналь хезмәт (торак хезмәте) күрсәтү белән тәэмин ителеше коэффициенты;

n – коммуналь хезмәт күрсәтүләр саны;

m – торак хезмәте күрсәтүләр саны;

j – муниципаль берәмлектәге уртача шартларга туры килә торган торак фондында күрсәтелә торган хезмәтләр исемлекләре.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 20 мае
№ 41-ТРЗ